**Республика Татарстан Сармановский муниципальный район Карашай Сакловское сельское поселение**
**423378 ул.Ленина д.100 с.Карашай Саклово Телефон: 885559 4-92-18**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай Саклау авыл жирлеге**
**423378 ,Карашай Саклау авылы, Ленин ур.100 йорты Телефон: 885559 4-92-18**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
« 04 » ноябрь 2024 ел № 3

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Чураш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, 18.1 статьясы нигезендә. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Уставы: 1.Чураш авылы мәдәният йорты бинасында, гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 15 нояберенә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә

2.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:«I группа инвалидлар , көндезге бүлек студентлары, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән, 2025 елда 600 сум үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне башкаруга тоту белән килешәсезме:

1.Чураш торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( юлларны кардан чистарту (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү, тракторчыга түләү)

2. Чураш Торак пункт территориясен төзекләндерү (кайнар нокта ветераннары өчен истәлекле стендлар сатып алу һәм урнаштыру; Чураш паркын койма белән әйләндереп алу, Беларусь МТЗ 82.1 тракторының ягулык-майлау материаллары сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу)

«ӘЙЕ» «ЮК?».

3.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, Чураш авылы торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Карашай-Саклау Советы Башлыгы

авыл җирлеге Башлыгы В. В. Хөсниева